

Мордовиядә «Эпромет» металлургия житештерvче завод; анда кабель йорәге - ток vткәрvче жеп туа. Монда киләчәк кабель очен алюминий һәм бакыр катанка чыгарыла, шуна кvрә кабель продукциясе житештерvдә катнашкан хезмәткәрләр турында сойләгәндә, без металлургия предприятиесе эшчеләре турында да сойлибез.
Теләсә кайсы предприятиенен уныш нигезе - vз эшенен осталары булган кочле кадрлар. «Эпромет» жәмгыятчелегендә 150 кеше эшли, аларнын кvбесе «Саранскабель»дән кvчкән. Алар арасында катанканы эшкәртv участогы мастеры Руслан Кәмил улы Арюков та бар. Ул «Эпромет» производствосынын Мактау тактасында vз урынын биләп тора.
Белеме буенча Кәмил улы Руслан инженер - механик, Н.П.Огарев исемендәге университетыбызнын механика һәм энергетика факультетын тәмамлаган. Предприятиегә аяк басканда яшь студент булган егет еллар дәвамында, акыллы остазлары ярдәме белән, тәжрибә туплаган. Хезмәт юлын «Саранскабель» сәvдә йортында башлый ул: башта эшче, смена мастеры, участок начальнигы, производствода житештерv буенча бvлек начальнигы булып эшли. Кабель житештерvдә 20 елга якын хезмәт куя.
«Эпромет» жәмгыятчелеге оештырылгач, аны беренчеләрдән булып металлургия житештерvен башлап жибәрvчеләр арасында чакыралар. Руслан Кәмил улынын бай тәжрибәсе, кыйммәтле белемнәре һәм тиешле кvнекмәләре яна эштә файдалы була.
Руслан Кәмилевич Арюков эше турында болай ди:
- Мина яна юнәлешне vзләштерv бик кызык иде, әмма бу vз - vземә яна бурычлар куйды. Мин моны булдыра алырмынмы икән дигән сорау да туган иде. Яна эш башлаганда шикләр һәрвакыт туа. Ана карамастан эшкә керешергә кирәк, эшли башлагач алар шунда ук таралалар. Чын-чынлап эшкә тотынгач, бар коченне шуна юнәлткәч, шиккә игътибар итәргә вакыт калмый, чонки бирелгән хезмәтне vтисе бар – алда эшлисе эш тора. Анын

топ бурычлары катанканы эшкәртv участогынын житештерv кvләме, хезмәт житештерvчәнлеген арттыру, продукциянен югары сыйфатын саклау буенча план кvрсәткечләрен vтәвен тәэмин итv. Шулай ук анын жаваплылыгы зонасына участокны материаллар һәм кирәк-яраклар белән тәэмин итv, хезмәткәрләрне укытуны оештыру, житештерv персоналынын эшен контрольдә тоту керә. Хәзер минем житәкчелектә тугыз кеше куелган бурычларны тормышка ашыра. Һәр эшнен унышы - бердәм команда эшендә. Ә бит инженер – чын ирләр һөнәре; катлаулы, әмма кирәкле, кызыклы, дәрәжәле һәм мактаулы. Руслан Кәмил улы Арюковнын тырыш хезмәтен житәкчеләр кvреп тора һәм торле-торле дәрәжәдәге бvләкләр белән бvләкләнә. Мәсәлән, кvпсанлы предприятие грамоталары һәм дипломнарынннан башка, Мордовия Республикасы сәнәгать, фән һәм яна технологияләр министрлыгы (Министерство промышленности, науки и новых технологий Республики Мордовия) ике грамотасы белән бvләкләгән. Ышанам, алда тагы зурлары котә аны.
Әйтеп китәргә кирәк, Руслан Кәмил улы Арюковнын матур гаиләсе. Диляра Рустам кызы белән ике бала – Самат белән Рамильне тәрбияләп vстерәләр. Гаиләдә рәхәтләнеп туган татар телендә сойләшеп, милли бәйрәмнәребезне бергәләп vткәрергә яраталар.

**Наилә НАСЫРОВА**